РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**2019 ел 18 сентябрь**

**КАРАР**
**№ 23**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. I, II төркем инвалидлардан, вакытлы хәрби хезмәт узучы гражданнардан, көндезге уку йортларында укучы студентлардан тыш, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Җыелган акчаларны түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга :
   - Иске Минзәләбаш авылының Октябрьнең 60 еллыгы һәм Октябрьнең 50 еллыгы урамнарына вак таш түшәү;
   - Иске Минзәләбаш авылында яктырткычларны алмаштыру;
   - массакүләм чаралар уздыру өчен бүләкләр сатып алу (Сабантуй, Өлкәннәр көне, Җиңү бәйрәме);
   -Беларусь 320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
   -Иске Минзәләбаш авылы обелискы өчен Бөек Ватан сугышында катнашучылар исемнәре язылган белән мемориаль такта сатып алу.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Иске Минзәләбаш авылы , Ленин урамы , 58 йорт.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үзем контрольдә тотам.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы рәисе

А.Р.Мияссарова